**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№131** **27.05.2019 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе турында**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен расларга (1 кушымта).
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.И. Нуриев**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең 2019 елның 27 маендагы 131 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү хакында Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба – ачык тыңлаулар) гамәлдәге законнар нигезендә үткәрелә.
2. Аргументацияләү өчен чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар булып Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Советына язмача гариза белән үз тәкъдимен юллаган җирлек халкы тора.
3. Ачык тыңлауларда, чыгыш ясау хокукыннан башка, җирлекнең барлык кызыксынган халкы катнаша ала.
4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланырга 30 минут кала башлана.
5. Ачык тыңлауларда рәислек итүче булып авыл җирлеге башлыгы тора.
6. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән башлана, ул утырышта катнашучыларга фикерләшә торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.
7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен, рәислек итүче тәкъдиме буенча җитәкче һәм секретариатның ике әгъзасы составында ачык тыңлауларның секретариаты сайлана.
8. Төп нотык белән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Советы депутаты чыгыш ясый.
9. Чыгыш ясау хокукы булган ачык тыңлауларда катнашучылар үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә чакырылалар.
10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык булырга тиеш түгел.
11. Ачык тыңлауларда катнашучылар утырыш тәмамланганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.
12. Катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аны туктатырга һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.
13. Катнашучыларның ачык тыңлауларны уздыру тәртибен үтәве ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.
14. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны залдан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.
15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, киңәшләрне ачыклау өчен секретариат җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.
16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язмача рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә. Ачык тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче имза сала һәм ул билгеләнгән

тәртиптә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Советы материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгак эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тынлаулар уздыруны оештыру һәм матди-техник тәэмин итү Зәй муниципаль районының Бохарай авыл җирлеге Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.